ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«07» август 2020 ел № 76-р

Муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең (ИНН 1601003713) 2020 елның 24 июленнән исх.№408 «Электр челтәрләре» ДУП махсуслаштырылган оешмасына электр челтәре объектларын тапшыру турында гаризасын өйрәнеп, кулланучыларны өзлексез энергия белән сыйфатлы тәэмин итү һәм энергия җиһазларын техник эксплуатацияләүнең сыйфат нормативларына туры килү максатларында, "Электр челтәрләре" ДУП ризалыгын исәпкә алып (ИНН 1655049111), Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2006 елның 27 декабрендәге 10-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милек реестры турындагы Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 06 мартындагы 46-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеген муниципаль милкеннән Татарстан Республикасы милкенә беренчел бәясе 322140 (өч йөз егерме ике мең бер йөз кырык) сум 00 тиен булган, Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тирсә ав., Восточная ур, 19 й. Адресы буенча урнашкан милекне тапшырырга:
   - КТП ТВ 400, 2010 елгы, бәясе 125223,00 сум;
   - трансформатор ТМ 400, 2010 елгы, бәясе 188786,00 сум;
   - приводлы өзгеч (разъединитель с приводом), 2010 елгы, бәясе 8131,00 сум.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге күрсәтмә кабул ителгән көннән алып 30 календарь көн эчендә кабул итү-тапшыру актларын рәсмиләштерүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Э.Р.Рыковага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Р. Вәлиев**